**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Чалпинского сельского поселения**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д.35, с. Чалпы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592) 35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**

Узэк урамы, 35, Чалпы авылы, 423324
Тел. (8-5592) 35-5-46, факс (8-5592)35-5-46
Chal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «23» сентябрь 2019 года №68

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Чалпы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылларында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылларында көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю территорияләрен җыештыру, чистарту;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында зиратлар өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу ;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылыдна янгын сүндергечләр, янгын ранецлары сатып алу;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында юлларны кардан чистарту;
- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында җәй көне территорияне чабу;

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында коры агачларны, куакларны кисү;

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Чалпы авылында һәйкәл кую ( мемориаль такта ачу);

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылына урам исемнәре язылган табличкалар ясату;

- Чалпы, Камышлы, Балан-Бүләк, Ирекле авылына су саклагычлар кырына «Су керү тыела» дип исемләнгән табличкалар ясату һәм урнаштыру;

- "Яна ел бәйрәме", "Җиңү көне", "Сабантуй", "Өлкәннәр көне" чаралары оештыру һәм уздыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Ленина ур., 130 йорт, Үзәк ур., 39 йорт, Чалпы авылы мәктэп бинасында, амбулатория бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Камышлы, Ирекле, Балан-Бүләк авыллары мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: А.М.Мөхәмәтшин